МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ
РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

Управление
Министерства юстиции
Российской Федерации
по Республике Татарстан

Хади Такташа ул., д.124, Казань, 420059
Тел./факс (843) 528-03-42
e-mail: ru16@minjust.gov.ru

_______________№_________________
На №___________от_________________

Главе
Пестречинского муниципального района
Республики Татарстан

Р.А. Сулейманову

**Уведомление о включении сведений о муниципальном правовом акте о внесении изменений в устав муниципального образования в государственный реестр уставов муниципальных образований Республики Татарстан**

Управление Министерства юстиции Российской Федерации по Республике Татарстан уведомляет о включении в государственный реестр уставов муниципальных образований Республики Татарстан решения Совета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан от 15.10.2024 № 353 «О внесении изменений в Устав Пестречинского муниципального района Республики Татарстан».

Дата государственной регистрации муниципального правового акта 15.11.2024.

Государственный регистрационный номер муниципального правового акта RU165330002024001.

15.11.2024 текст муниципального правового акта размещен на портале Министерства юстиции Российской Федерации «Нормативные правовые акты в Российской Федерации» в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф).

С уважением,
заместитель начальника А.И. Галяутдинов

Пашкова М.А.
(843) 528-03-42 доб. 801

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының кырык җиденче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

15 октябрь, 2024 ел № 353

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 92, 93, 94 статьялары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2015 елның 21 маендагы 41/235 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2016 елның 5 февралендәге 31, 27 декабрендәге 77, 2017 елның 13 июлендәге 100, 2018 елның 17 гыйнварындагы 126, 2018 елның 24 июлендәге 153, 2019 елның 28 февралендәге 183, 2019 елның 5 декабрендәге 234, 2020 елның 26 октябрендәге 21, 2021 елның 29 декабрендәге 135, 2022 елның 11 августындагы 180 номерлы, 2023 елның 23 ноябрендәге 279 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) район газетасының вакытлы матбугат «Вперед» («Алга») басмасында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Россия Юстиция министрлыгының хокукый порталында «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» (http://pravo-minjust.ru, http://хокук-минюст.рф) урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карарына кушымта
15 октябрь, 2024 ел № 353

## Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. «Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре»6 статьясының 1 өлешендә:

а) 9 пунктка «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү»сүзләрен өстәргә.;

б) 27 пунктта «муниципаль район территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга.;

в) 33 пунктта «, шулай ук рекреацион максатларда су объектларыннан файдалану кагыйдәләре» сүзләрен өстәргә.

2. «Муниципаль контроль» 9 статьясының 2 өлешендә «Россия Федерациясендә муниципаль контрольгә дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында «2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның» сүзләрен «Россия Федерациясендә муниципаль контрольгә дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында «2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның» сүзләренә алмаштырырга.».

3. «Район Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты статусы»31 статьясында:

а) б) 3 өлешнең 12 пунктындагы пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш) Татарстан Республикасы башлыгына (рәисенә) алдан хәбәр итеп.

Хәбәрнамә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә кәгазьдә яисә Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы аша җибәрелә.

Хәбәрнамәгә муниципаль вазыйфаны биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы зат түләүсез нигездә катнашырга ниятләгән коммерциячел булмаган оешма уставының күчермәсе һәм коммерциячел булмаган оешманың идарә органы турындагы нигезләмәнең күчермәсе (мондый нигезләмә булганда) кушып бирелә;»;

б) 6 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 10.1 пункт өстәргә:

«10.1) аның чит ил агенты статусын алуы; ».

4. «Район Советы компетенциясе» 34 статьясындагы 1 өлешенең 13 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

5. «Район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 40 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 6.1 пункт өстәргә:

«6.1) аның чит ил агенты статусын алуы; ».

5. «Башкарма комитет вәкаләтләре»49 статьясында:

а) 1 өлештә:

- 1.3 пунктның 2 пунктчасында «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыра һәм үткәрә» сүзләрен өстәргә.;

- 1.3 пунктның 4 пунктчасында «район территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыра, үстерә һәм саклауны тәэмин итә, шулай ук" сүзләрен төшереп калдырырга:

- 1.8 пунктның 5 пунктчасында «, шулай ук су объектларыннан рекреация максатларында файдалану кагыйдәләрен»сүзләрен өстәргә.;

- 1.9 пунктның 3 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыра;»;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Районның башкарма комитеты Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора.

Район Башкарма комитетының муниципаль контроль өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда муниципаль контроль өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;

2) район территориясендә муниципаль контроль оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) «Россия Федерациясендә муниципаль контрольгә дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә башка вәкаләтләр.

Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру функцияләре мондый органнарның статусын билгели торган хокукый актлар нигезендә район Башкарма комитеты органнарына йөкләнергә мөмкин.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга тикшерүләр оештыруга һәм уздыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата «Россия Федерациясендә муниципаль контрольнең дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.».

8. 65 статьяның 3 өлешендә «район Советы депутаты, башка вазыйфаи затлар эшчәнлегенең социаль һәм башка гарантияләре» сүзләрен төшереп калдырырга.

7. «Муниципаль хокукый актларның үз көченә керүе һәм халыкка җиткерелүе»79 статьясында:

а) 2 өлештә «шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләрне» сүзләреннән соң «җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрен гамәлгә ашыру турындагы килешүләрне» сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлештә «шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләрдән» сүзләреннән соң «җирле үзидарә органнарының халыкара һәм

тышкы икътисадый элемтәләрен гамәлгә ашыру турындагы килешүләрдән»сүзләрен өстәргә.

в) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән Килешүне, җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрен гамәлгә ашыру турындагы килешүне халыкка җиткерү дигәндә аңлашыла:

1) «ТАТМЕДИА» АҖ филиалының Питрәч районы газеталарында муниципаль хокукый актны рәсми бастырып чыгару: «Вперед» (ПИ № ФС7-4736) һәм Алга («Вперед») (ТУ16 - 01021 номерлы ПИ теркәлүе турында таныклык), «Алга» («Вперед») челтәре басмасы (Эл № ФС77-47629 теркәлүе турында таныклык), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (ЭЛ № 77 - 60244) теркәлү турында таныклык (ЭЛ № ФС-77-60244);

2) Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Совет урамы, 18 йорт адресы буена муниципаль хокукый актны район җирле үзидарә органының мәгълүмат стендында урнаштыру;

3) муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында (https://pestreci.tatarstan.ru/) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру;

г) 5 өлештә «шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне дә» сүзләреннән соң «җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрен гамәлгә ашыру турында килешүләр» сүзләрен өстәргә;

д) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне, җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрен гамәлгә ашыру турында килешүне рәсми бастырып чыгару «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Районда Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Совет урамы, 18 нче йорт адресы буенча җирле үзидарә органы бинасында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташтыру пункты булдыру тәэмин ителә.»;

е) 7 өлештә «шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр» сүзләреннән соң «җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрен гамәлгә ашыру турында килешүләр» сүзләрен өстәргә.